БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 июнь 2026 ел №56

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Балтач районы прокурорының 2026 елның 10 апрелендәге 02-08-01-2026/Прдп146-26-20920011 номерлы протестын карап, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2021 елның 8 ноябрендәге 79 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә (2025 елның 30 апрелендәге 318 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 33.5 пункт өстәргә:

«33.5. Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) махсус режимы кысаларында профилактик визит үткәрү турында, кисәтү игълан итү турында, контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында карарлар, контроль (күзәтчелек) чарасы, профилактик чара, контроль (күзәтчелек) гамәлдә булу актлары (шул исәптән уздыру мөмкинлеге булмау турындагы актлар), ачыкланган хокук бозуларны бетергәндә контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына алар турында белешмәләр кертү һәм аларга имза салу юлы белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән карарларны, актларны һәм күрсәтмәләрне рәсмиләштерү өчен документны аерым төзү таләп ителми.».

1.2. 34.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«34.2. Мәҗбүри профилактик визит контрольдә тотылучы затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый. «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә контрольдә тотылучы затка мәҗбүри профилактик визит уздыру турында ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.».

1.3. 54 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Документлар контрольдә тотылучы затлар тарафыннан бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын, региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын яисә «Инспектор» мобиль кушымтасын кулланып тапшырылырга мөмкин.».

1.4. 61 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«урынга чыгып тикшерүләрне уздыру срокларына һәм урынга чыгып тикшерүләр уздыру барышында кече эшкуарлык субъектлары белән үзара хезмәттәшлек итү срокларына карата әлеге пунктта билгеләнгән таләпләрнең гамәлдә булуы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга кагыла, аларның кече предприятиеләр өчен хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны алдагы календарь елда «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1.1 өлешенең 2 пунктында билгеләнгән иң чик күрсәткечтән артмый, ә микропредприятиеләргә - социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, урынга чыгып тикшерүләр уздыру өлешендә аларның хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны алдагы календарь елда микропредприятиеләр өчен күрсәтелгән пунктта билгеләнгән иң чик күрсәткечтән артмый. Әлеге өлешнең нигезләмәләренең гамәлдә булуы Россия Федерациясе Салым кодексының 265 статьясындагы 1 пунктының 19.6 пунктчасы нигезендә төзелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга кагыла.».

1.5. 35 пунктның «е» пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«е) урынга чыгып тикшерү (карау, инструменталь тикшерү (видеоязма кулланып), пилотсыз аппаратлар (системалар) кулланып).».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Балтач муниципаль район Башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин